**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына үзгәрешләр кертү турында

Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы һәм 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ау параметрларының III кисәгенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктның 1 пунктчасы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аксубай» аучылык хуҗалыгы;»;

б) 4 пунктның 2 пунктчасы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үрнәк» аучылык хуҗалыгы»;»;

в) түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 пунктлар өстәргә:

«7. 2017 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасының барлык аучылык биләмәләрендә ак куянга, суерга, бөҗырга һәм соры көртлеккә һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

8. 2015-2016 еллар ау сезонында «Аксубай», «Беркут», «Бутино-Чишмә», «Арча», «Үрнәк», «Әтнә», «Юкә», «Буа», «Глухарь», «Фазан», «Алабуга», «Караеш», «Зеленодольск», «Кызыл Октябрь», «Идел-Кама», «Камское раздолье», «Рысь», «Яңа Минзәлә», «Сухарево», «Чишмә», «Красновидово», «Төрнәс», «Тәтеш», «Уракчы», «Мизин» аучылык хуҗалыкларыннан һәм Әлки, Әлмәт, Чүпрәле, Лениногорск, Балык Бистәсе

районнарының  ачык аучылык биләмәләреннән тыш, барлык аучылык биләмәләрендә соры куянга һәвәскәрләр авы  һәм спорт авы тыела.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 15 август
№ ПУ-724